РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» 05 2021 ел № 398

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Башкарма комитетының «Ютазы
муниципаль районы территориясендә гомуми
таралган файдалы казылмалар чыгарганда,
шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле
булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә,
җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга
муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның
административ регламентын раслау турында"
12.03.20021 ел, № 167 карарына үзгәрешләр
кертү хакында

Россия Федерациясе «Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Законының 5 статьясындагы 5 пункты, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, "Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 апрелендәге 275 номерлы карары нигезендә, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Ютазы муниципаль районы территориясендә гомуми таралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 12.03.2021 ел, № 167

карарына (алга таба - Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

1.1.Административ регламентның 6.9 пунктының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка килгән шикаятькә җавап, шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, һәм почта адресы шикаятьтә язма рәвештә күрсәтелгәндә, язма рәвештә, күрсәтелгән адрес буенча җибәрелә. Моннан тыш, Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы шикаятькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять белдерелә торган мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатуга бәйле рәвештә, "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 02.05.2006 ел, № 59-ФЗ Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше таләпләрен үтәп, Ютазы муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.»

2. Әлеге карарны https://jutaza.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат пталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Е. С. Огнева
2-76-31